**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «23» декабреннән № 372

Татарстан Ресаубликасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2021 елның 7 сентябрендәге 842 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга айлык акчалата һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2022 елның 01 сентябрендәге 934 номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елның 01 октябреннән Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020 елның 12 октябрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының аз керемле гаиләләрендә укучыларны түләүсез тукландыруны тәэмин итү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көнендә 8 сум 30 тиен (2022 елның 31 декабренә кадәр) һәм 8 сум 80 тиен (2023 елның 1 гыйнварыннан) күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар аш белән тәэмин итәргә;

1.2 аз керемле гаиләләрдән булган укучылар өчен җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, 36 сумлык кайнар иртәнге ашлар оештырырга;

1.2.1. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) укучыларны җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр ашатуны оештырырга:

1-4 класслар 2022 елның 01 октябреннән 2022 елның 31 декабренә кадәр бәясе 55,55 сум һәм 36 сум, 2023 елның 01 гыйнварыннан 2023 елның 31 маена кадәр бәясе 64,19 сум һәм 36 сум;

5-11 класслар 2022 елның 01 октябреннән 2022 елның 31 декабренә кадәр бәясе 8,3 сум һәм 36 сум, 2023 елның 01 гыйнварыннан 2023 елның 31 маена кадәр бәясе 8,8 сум һәм 36 сум.

1.2.2. 2022 елның 1 октябреннән 2023 елның 31 маена кадәр ата-аналары яки законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнашу өчен мобилизацияләнгән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын җирле бюджет акчалары исәбеннән, шул исәптән субсидияләрне кертеп, 36 сумлык ике тапкыр бушлай тукландыруны оештырырга.

1.3. 5 көн эчендә бушлай тукландыру өчен 1.2 пунктта күрсәтелгән категорияләр буенча укучылар исемлеген бирергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына аз керемле гаиләләрдән булган балаларны бушлай тукландыруны оештыру чыгымнарын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауны башкарырга.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә:

3.1. витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләр балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә;

3.2. укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны тикшереп торуны тәэмин итәргә;

3.3 мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашлары ассортиментын баету буенча эшне көчәйтергә;

3.4 гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез китерелүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү учреждениеләре һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:

4.1 мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

4.2 гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә производство контролен башкарырга.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез туклануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар 2002 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2002 елның 01 октябреннән Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2022 елның 29 сентябрендәге 275 номерлы карары (2022 елның 06 октябрендәге 280 номерлы, 2022 елның 14 ноябрендәге 330 номерлы, 2022 елның 21 ноябрендәге 341 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов